**СОВЕТ ШАПШИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422708 Республика Татарстан, Высокогорский район, с. Шәпши, ул. Ленина, 1

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШӘПШИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422708, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Шәпши авылы, Ленин ур., 1

тел./факс 8(84365) 77-2-36, e-mail: Shap.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**01.04.2021 г.** **№ 21**

**Советның 2019 елның 23 июлендәге 156 нчы номерлы Карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының «Шәпши авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә, «Шәпши авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Шәпши авыл җирлеге Советы,

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Шәпши авыл җирлеге Советының 2019 елның 23 июлендәге 156 нчы номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Шәпши авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты турындагы Нигезләмәне раслау турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Шәпши авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты турындагы Нигезләмәнең (Советның 13.08.2019 №158, 07.09.2020 №190 карары редакциясендә) 3 бүлегенең 3.3. пунктына түбәндәге эчтәлекле 17 пункт белән тулыландырып үзгәрешләр кертергә:

«17) алкогольле, наркотик яисә башка токсик исереклек халәтендәге затларга ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру.».

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендәге Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталының рәсми сайтында http://pravo.tatarstan.ru бастырырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге Башлыгы В.А.Беляков